ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАНАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

02.04.2018 д. Канаш №6

2018 елгы язгы ташу чорында Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге халкын һәм территориясен яклау чаралары турында

Санитар-эпидемиологик хәлнең имин булуын тәэмин итү, халык арасында, шул исәптән су юлы белән тапшырыла торган массакүләм йогышлы(йогышлы булмаган) авырулар барлыкка килүне кисәтү, 2018 елгы язгы ташуның тискәре санитар-эпидемиологик нәтиҗәләрен булдырмау максатларында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елгы язгы ташу чорында Татарстан Республикасы халкын һәм территориясен саклау чаралары турында»2018 елның 14 февралендәге 85 номерлы Карарын үтәү йөзеннән һәм 2018елның язгы ташу чорында халыкның, торак һәм хуҗалык объектларының, гидротехник корылмаларның, юлларның һәм күперләрнең гадәттән тыш хәлләрен булдырмау һәм аларны яклау максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. 2018 елгы язгы ташу чорында халыкны һәм Канаш авыл җирлеге территориясен яклау буенча чаралар планын расларга.(1нче кушымта).
2. Канада авыл җирлеге территориясендә 2018нче елгы су басуларга каршы чаралар башкаруны тәэмин итү буенча гадәттән тыш хәлләр һәм санитар-эпидемиологик вәзгыять буенча комиссиянең эш төркемен төзергә (2 нче кушымта).
3. Язгы ташу чорына эш төркеме әгъзалары булган Канаш авыл җирлеге башкарма комитетында җаваплы хезмәткәрләрнең кизү торуын билгеләргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Вальков

1 нче кушымта

2018нче елгы язгы ташу чорында Югары Ослан районының Канаш авыл җирлеге халкын һәм территориясен яклау чаралары
ПЛАНЫ

| № т/б | Чаралар исеме | башкаручылар | Үтәү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | Канаш авыл җирлеге территориясендә язгы ташу чорына ЧС буенча эшче төркем оештыру | Канаш АҖ башлыгы | 03.04.2018 |
| 2 | ЧС буенча язгы ташуның эпидемиологик нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм язгы ташу чорында оешмаларның һәм хезмәтләрнең әзерлеге мәсьәләләре буенча эш төркеме утырышын үткәрү. | Канаш АҖ башлыгы | 04.04.2018 |
| 2 | Территорияләрне кардан чистарту мәсьәләләрен хәл итү буенча эшне активлаштыру | Учреждениеләр җитәкчеләре<br>- | 2018 елның 10 апреленә кадәр |
| 3 | Торак пункт буенча кар суларын агызу юлларын чистартырга | АҖ башлыгы | 2018 елның 10 апреленә кадәр |
| 4 | Кардан каптажлар территориясен чистарту һәм эчә торган суның сыйфатын тикшереп тору | АҖ башлыгы | Март-апрель 2018 |
| 5 | Медицина һәм дару чаралары, шул исәптән эпидемия күрсәткечләре буенча халыкны ашыгыч профилактикалау өчен кирәкле препаратлар (язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу очрагына иммунизация һәм фагирование) тәэмин итү | АҖ башлыгы<br>- Канаш ФАПы мөдире | 2018 апрель |
| | | | |

Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Вальков

2 нче кушымта

2018 елда язгы ташуга каршы чараларны үтәүне тәэмин итү буенча Канаш авыл җирлегенең гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча эшче төркем составы

1. Вальков Н.Н - Канаш авыл җирлеге башлыгы
2. Баймяшкина О.С. Канаш авыл клубы мөдире
3. Андреев С.Е - «Идел буе урманчылыгы» ДКУ урман мастеры
4. Иванов В.Н. - «Волжанка» тракторчысы

Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Вальков